Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 июнь 2020 ел №382

Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 2 октябрендәге «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә турында»гы 402 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 24 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 2 октябрендәге «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шулай ук керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә турында»гы 402 нче номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 425 номерлы, 2015 елның 7 августындагы 484 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 2 бүлеге 2.1 пункты икенче абзацында «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарәгә кагылышлы сораулар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Багманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов